КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 декабрь г.Казань № 1210

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль түләүләре турындагы мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы хакында» 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль түләүләре турындагы мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы хакында» 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 май, 323 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2012 ел, 30 ноябрь, 19н» сүзләрен «2017 ел, 12 май, 11н» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктка «ярдәмендә» сүзеннән соң «яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен үтәгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен үтәгәндә ведомствоара мәгълүмати хез-

мәттәшлек итү тәртибе нигезендә турыдан-туры, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештереп,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль түләүләре турындагы мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы хакындагы нигезләмәдә:

1.2 нче пунктта:

«2012 ел, 30 ноябрь, 19н» сүзләрен «2017 ел, 12 май, 11н» сүзләренә алыштырырга;

«(алга таба – 19н боерыгы)» сүзләрен «(алга таба – 11н боерыгы)» сүзләренә алыштырырга;

1.3 нче пунктта «19н боерыгындагы» сүзләрен «11н боерыгындагы» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин